№ 44 (1171), 27 октябрь 2012 ел
4 Бердәмлек



ларга тоту начар санала. Байлыкны исә шәригать күрсәткән урыннарга тоту бик тә яхшы санала.

Икенче төркем кешеләргә килгәндә, алар иң яхшы дәрәҗәдә булмасалар да, яхшы кешеләр итеп саналалар, чөнки аларның гыйлемнәре бар. Гыйлеменә карата алар тәкъвалык күрсәтәләр. Аллаһының хакларын үтиләр. Мөлкәтләре булмаса да, әгәр малым булса, яхшы гамәлләр кылыр идем, дип нияттә торалар. Аллаһы Тәгалә аларга моның өчен әҗер-савап бирә.

Өченче төркем гыйлемсез булып, мөлкәтен үз белдеге белән сарыф итә, хәрәм эшләргә аны җибәрә, Аллаһының хакын хакламый, зәкят-садакаларны бирми. Шуның өчен ул начар гөнаһлы төркем диелә.

Дүртенче төркемдә исә малы да, гыйлеме дә юк. Шуңа өстәп, аның нияте дә бозык. Малым булса, хәрәм эшләрне эшләр идем, дип теләп тора. Ниятенә карата ул гөнаһ ала.

**Вәлиулла хәзрәт ЯГЪКУБ.**
*("Иман" газетасыннан)*

# Әдәп сәдәптән башлана

Халык педагогикасы тәрбияне өч чорга бүлеп карый. Шуның беренчесе – ана мәктәбе. Ул, бисмилләһ әйтеп, сабыйны тәүге тапкыр кулыңа алу һәм изге күкрәк сөте имезүдән башлана.

Бу ләззәтле минутлар мөселман хатыннары тарафыннан шул дәрәҗәдә ипле, сабыр итеп башкарыла ки, сокланып таң каласың: чәчбаш нәфис, ак яулык ябылган, карашында горурлык катыш оялу-читенсенү. Ананың бу халәте, минемчә, күкрәк сөте белән сабыена күчә, ягъни тыйнаклык тәрбияләүнең беренче адымнары ясала. Кулына нарасыен алган теләсә кайсы ананың күңеленә изге теләкләр генә киләдер, якты өмет кенә уянадыр ул.

Әмма, ни хикмәт, җәмгыятебезнең нәкъ менә тормышны дәвам иттерүче өлеше – байтак нәфис затларыбыз бүген ирләргә караганда да бозыграк. Быел, җәй көне, йомышым төшеп, берничә кат Бауман урамыннан үтәргә туры килде. Турысын язуыма гафу итегез, мин анда бөҗра тагылган йөзләгән кендек күреп хәйран калдым. Голливуд киносымыни! Уңда да кендек, сулда да кендек. Берсе дә ир-атныкы түгел. Хатын-кыз чишенгән! Бу кыланышны бер генә төрле – мал базарындагы кебек, үз тауарыңны сатып алучыларга тәкъдим итү, дип аңларга була... Анадан тума диярлекләре бар. Бу рисвайлыктан оялып тукталышка ашыгам.

Троллейбуска кереп утыру белән күзләрем алгы мәйданчыкта басып торган ике кыз балага бага. Рәхмәт төшкерләре. Гәүдәләренә килешле итеп тегелгән озын итәк, озын җиңле нәфис блузка кигәннәр, башларында яулык. Йөз-бит, күз-каш, керфек-иреннәрдә буяуның эзе дә юк. Һәр җирләре табигый, Аллаһы яратканча. Аларга сокланып, күзем, җаным ял итәргә дә өлгерми, ирексездән, бер сөйләшүнең шаһиты булам. Янымда гына торган бер егет белән кыз да әлеге туташлар турында фикер алыша икән. Сүзне егет башлый:

– Кара әле, сиңа әнә теге кызлар ошыймы?

– Юк, ошамый!

– Ә миңа ошый.

– Ни таптың инде аларда? Әби сыман яулыкка уралганнар.

– Алардагы серлелек ошый миңа. Минем аларның муеннарын күрәсем, чәчләреннән сыйпыйсым, итәк астына яшерелгән аякларының матурлыгына сокланасым, кул җылысын тоясым килә. Ә синдә бу серләр инде калмаган, бар да капшалган, җәмәгать күзәтүенә тапшырылган...

Әйе, хатын-кызларыбызның яулыгы – матбугатта да, эфирда да, халык авызында да иң күп тикшерелгән темаларның берседер, мөгаен. Аны хәтта судка да бирделәр бит инде. Бу гамәлне мин яулыкны түгел, ә әхлакны хөкем итү дип карадым. Шул яулык бәйләгән сылулар турында «мескеннәр», «ваһһабчылар», «нигә яулыкны төрекчә бәйлисез?», «яулык бәйләү – чираттагы мода гына, бетәр әле», дип һәм тагын әллә ниләр сөйләделәр, сөйлиләр. Хәтта кайбер мәртәбәле, зыялы затларыбызда яулык ябуны «кылану» дип кенә кабул итә. Шушы урында Коръәннән бер аять китерим әле.

*«И, Мөхәммәд, мөэмин ирләргә (хәрәмгә) күз атарга ярамаганны (җенси вәсвәсәгә, азгынлыкка бирелмичә), намус пакьлеген сакларга кирәклеге турында сөйлә...»*

*«Мөэминә хатын-кызларга да сөйлә: (ярамаганнарга караудан) тыелсыннар; намус һәм гыйффәтләрен сакласыннар. Күрсәтергә яраганнардан (йөз белән куллардан) башка зиннәтләрен күрсәтмәсеннәр. Баш яулыклары муеннарын, якаларын, күкрәкләрен каплап торсын... Яшерелгән зиннәтләре беленсен, күренсен, дип (ирләрнең игътибарын тартырдай итеп) каты басмасыннар».* («Нур» сүрәсе, 30-31 аятьләр).

Яулык бәйләү бары тик Аллаһы кушканча, күренергә тиеш булмаган урыннарны каплау гына икән. «Кылану» да, мода да түгел. Иманы нык булган хатын-кызларыбыз өчен бу «мода» үтеп тә китмәс. Күрәсез, аны ничек бәйләү турында да әйтелмәгән - теләсәң ничек яп. Бу аятьләр яулык ябуның бары әхлак нормалары, пакьлек һәм намусны саклау, фахишәлеккә киртә кую икәнен дәлилләмимени?

Кимсетмик яулыкны, һәм аны япкан сылуларны артта калган, надан кеше, дип тә карамыйк. Аларның юлы туры. Араларында өчәр-дүртәр тел белүчеләре бар. Җәмгыятебезне чистарту юлында зур эш башкаралар бит алар. Мөселманнарның исламда булуларын дәлилләгән белешмәләр дә сорамыйк. Бу бер Аллаһыга гына мәгълүм сыйфат. Аллаһы Тәгалә һәммәбезгә дә тәүфыйк-һидаятьләр бирсен.

**Флюра ХАННАНОВА,**
**Россиянең мәгариф отличнигы,**
**«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимәсе.**
("Татар мөселман календаре"ннан)



*Гаделлек иясе — бер Аллаһыма*
*Ничек җавап бирермен?*
*Монда килгәнемне белгәч,*
*Ничек итеп түзәрмен?*

*Соңгы юлым тәмамланды,*
*Менә зират капкасы.*
*Каберем ачык, мине көтә,*
*Ничек кереп ятасы.*

*Акка төренгән гәүдәмне*
*Алды җир кочагына.*
*Тезелеп Коръән укыдылар*
*Утырып баш очыма.*

*Киттеләр...Калдым ялгызым,*
*Берегез белми хәлне.*
*Килеп керер шул чагында*
*Җаным эзләп тәнемне.*

*Сорауларга төгәл җавап*
*Ничек кенә бирермен?*
*Бер Ходаем бары Синнән*
*Ярдәм өмет итәрмен.*

*Аллаһы кушса, изгелекләрем*
*Басар үлчәү мизанын.*
*Вәгъдә кылган җәннәтләргә*
*Илтсә иде сукмагым.*

*Ишек-тәрәзәсез өем,*
*Авыр туфрак өстемдә.*
*Сынау өчен без барыбыз*
*Киләбез бит өч көнгә.*

*Каберем өстенә таш куегыз,*
*Чәчәк-гөл утыртыгыз.*
*Сирәк булса да, ирем, улым,*
*Коръән укып китегез.*

***МӨНӘҖӘТ***

# Югалту

**(Хәләл җефетемә багышлыйм)**

*Каберәңә барам, дога кылам,*
*Исемә төшә бергә вакытлар,*
*Гомер юлым синең белән үткән,*
*Синең белән тойдым шатлыклар.*

*Каберәңә барып чәчкә куям,*
*Нурлы булып торсын каберең.*
*Белмәгәнбез икән исән чакта*
*Бергә яшәүләрнең кадерен.*

*Мин ялгызым түгел, балалар бар,*
*Син ятасың анда берүзең.*
*Йөрәгемә шифа булып калды*
*Исән чакта әйткән һәр сүзең.*

*Үз яныңда пар канатың булсын,*
*Дөрес әйтәләр бит бу сүзне.*
*Син булмагач, тормыш яме бетте,*
*Кояш та күк минем өчен сүнде.*

*Соңгы, бәхилләшү минутында*
*Бик нык сыкрады шул йөрәгем.*
*Күземә карап, ахыр сүзең әйттең:*
*"Бәхил бул инде, - диеп, - кадерлем".*

**Юмабикә УСМАНОВА.**
Самара шәһәре.




**- Кайберәүләр фарыз намазда дога кушып укырга ярамый, ди. Ә бервакыт болай эшләүнең сәбабы зур, дип язылганны укыдым. Дөресе ничек була?**

- Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә ничек кушкан һәм Пәйгамбәребез Мәхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм фарыз намазын ни рәвешле укыган, без дә нәкъ шулай укырга тиешбез. Үзебездән бернәрсә дә куша алмыйбыз. Фарыз намазда бары ике җирдә генә дога укыла: «Раббәнә» һәм «Үәл-икрам». Ә инде Коръәннән нинди сүрә укуыбыз – анысы үзебездән тора. Дога дигән сүз теләк дигәнне аңлата һәм ул русча да, кытайча да, японча да, немецча да, татарча да булырга мөмкин. Ә фарыз намазда чит сүзләр кушарга ярамый.

* * *

**- Корбан чалгач, намаз уку фарызмы?**

- Корбан чалгач, намаз уку фарыз да түгел, важиб тә түгел, сөннәт тә түгел. Ул мөстәхәб дип әйтергә була. Нәфел намазын теләгән кеше укый, теләмәгәне укымый. Укып Аллаһы Тәгаләдән корбанлыкның кабул ителүен сорау – мөстәхәб гамәл, һәркемнең үз ихтыярында.

* * *

**- Коръәнне көй (мәкам) белән уку гөнаһ диеп ишеттем. Бәлки, ялгыш сүздер бу. Әнием көйләп өйрәтә иде. Ничек дөрес була икән?**

- Коръәнне тәҗвидкә туры китермичә, ниндидер көйгә салу - хәрәм. Кайда сузарга ярый, кайда ярамаганлыгын, ягъни тәҗвид кагыйдәләрен белмәгәндә, хәрефе белән булса да укырга кирәк, сузмыйча гына. Сузып, көйләп укыйсың икән – анда тәҗвид кагыйдәсенә туры китерү тиеш.

*("Дин вә йола" газетасыннан)*